КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 25 декабрь г.Казань № 1222

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кичектергесез оператив хезмәтләрне чакырулар турындагы мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү, мәгълүматлар базаларын төзү һәм алып бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2015 ел, 10 март, 142 нче карары белән расланган Кичектергесез оператив хезмәтләрне чакырулар турындагы мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү, мәгълүматлар базаларын төзү һәм алып бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кичектергесез оператив хезмәтләрне чакырулар турындагы мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү, мәгълүматлар базаларын төзү һәм алып бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2015 ел, 10 март, 142 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 9 февраль, 75 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Кичектергесез оператив хезмәтләрне чакырулар турындагы мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү, мәгълүматлар базаларын төзү һәм алып бару буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта:

унтугызынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

егерме беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының «Россия Россия нумерация системасын һәм планын раслау турында» 2017 ел, 25 апрель, 205 нчы приказы;»;

егерме алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыруны тәэмин итү системасын үстерү турында» 2018 ел, 20 февраль, 103 нче карары;»;

егерме җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

12 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын үтәмәгән өчен шикаятьләр бирү, теркәү һәм карау тәртибе

12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга шикаять (алга таба – шикаять) «112 нче хезмәт» учреждениесенә кәгазь чыганакта язма рәвештә яки электрон рәвештә тапшырыла. «112 нче хезмәт» учреждениесе җитәкчесе кабул иткән карарларга карата шикаятьләр Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына бирелә.

12.2. Шикаять почта буенча, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, «112 нче хезмәт» учреждениесенең рәсми сайтыннан, Россия Федерациясе дәүләт хезмәтләре күрсәтү порталыннан (www.gosuslugi.ru) йә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (uslugi.tatarstan.ru) файдаланып җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә алынырга мөмкин.

12.3. Шикаять законнарда билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә тиеш.

12.4. Шикаять ул кергән көннән 3 календарь көн эчендә мәҗбүри теркәлергә һәм аны теркәгән көннән 15 эш көне эчендә шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат тарафыннан каралырга тиеш.

12.5. Шикаятьләрне карау нәтиҗәләре буенча «112 нче хезмәт» учреждениесе дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар нигезендә карар кабул итә һәм аны кабул иткән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон рәвештә нигезле җавап җибәрә.

12.6. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле булган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

12.7. Шикаятьне канәгатьләндерү кирәк түгел дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында аргументлаштырылган аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

12.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланса, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичектергесез рәзвештә прокуратура органнарына җибәрә.

12.9. Гариза бирүче «112 нче хезмәт» ДБУ вазыйфаи затларының дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин